**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авылы җирлеге Югары Яхшый авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

28 ноябрь 2025 ел № 4

“Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принципалары турында” 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Актаныш муниципаль районының Югары Яхшый авылы җирлеге Югары Яхшый авылында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: “Сез 2026 елда бер тапкыр түләнә торган, Югары Яхшый авыл җирлеге Югары Яхшый авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышы инвалидларыннан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 1 группа инвалидлар, студентлар, көндезге формада укучылардан тыш, җирлектәге түбәндәге эшләрне башкаруга 600 сум үзара салым кертү белән килешәсезме?:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктырту челтәрләрен тоту һәм ремонтлау);

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су үткәрү челтәрләрен карап тоту һәм ремонтлау);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (грейдерлау, җәйге һәм кышкы юлларны карап тоту);

- торак пункт территориясен төзекләндерү ( авылга керу стелласы урнаштыру);

- ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (зиратка койма тоту).

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 98 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 62 граждан кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«риза» позициясе өчен 62 граждан тавыш бирде;
"каршы" позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.
"тоткарланучылар" позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Югары Яхшый авылы җирлеге Югары Яхшый авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: “Сез 2026 елда бер тапкыр түләнә торган, Югары Яхшый авыл җирлеге Югары Яхшый авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышы инвалидларыннан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 1 группа инвалидлар, студентлар , көндезге формада укучылардан тыш, җирлектәге түбәндәге эшләрне башкаруга 600 сум үзара салым кертү белән килешәсезме?:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктырту челтәрләрен тоту һәм ремонтлау);

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су үткәрү челтәрләрен карап тоту һәм ремонтлау);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (грейдерлау, җәйге һәм кышкы юлларны карап тоту);

- торак пункт территориясен төзекләндерү ( авылга керү стелласы урнаштыру);

- ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (зиратка койма тоту), кабул ителгән дип танырга.

3. Аерым мәсьәләләр буенча экономия ясалган очракта, Югары Яхшый авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенында билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

4. Югары Яхшый авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында әлеге карарны игълан итәргә, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга - http://aktanysh.tatar.ru

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Актаныш муниципаль районы
Югары Яхшый авыл җирлеге Башлыгы ____________ Әхәтов И. Х.